“АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”

# Чишмә башы

№ 1
Сентябрь
2025 ел

**Әти-әниләр һәм балалар өчен татарча гәҗит**

## *Көзге табигать кочагында*

Көз-үзе моңсу, шул ук вакытта күңелле дә ел фасылы. Моңсу дип җылы җәй белән саубуллашканга әйтәбез, күңелле, чөнки көз-мул уңыш җыю мөмкинлеге бирә,табигать тә матур алтынсу төсләргә бай була. Һәркемнең туган җиренең, туган авылының матур табигате була. "Табигать" — бу бик кадерле сүз. Кемгә дә газиз, якын, кадерле бит ул! Ә туган якның табигате, һәр карыш җире, авылы, чишмәсе, басу-кырлары, урман-болыны әллә никадәр истәлекләр саклый. Кешеләрне гүзәл табигать иркәли, яшәргә шартлар тудыра. Шуңа күрә табигатебезне яратыйк, саклап яшик.

### Табигатьне саклау- безнең изге бурычыбыз

Без - табигать балалары:
Уллары һәм кызлары.
Саклыйк әле табигатьне!
Саклыйк әле Җир шарын!

Көз - табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтү өчен иң кулай вакыт. Аларны күрү өчен, табигать кочагында булу кирәк.Чөнки табигать кочагында булу балалар өчен һәрвакыт кызыклы вакыйга. Октябрь аеның җылы бер көнендә, балалар белән бергә табигатькә чыктык. Без анда нәрсәләр күзәттек соң? Башта без күк йөзенең матур буяуларына, яфракларның матур бизәкле булуына сокландык, табигатьнең матур авазларын тыңладык. Балалар белән табышмаклар чиштек, сорауларга җаваплар таптык, халык сынамышларын искә төшердек. Тере һәм тере булмаган табигатькә, табигый сезонлы үзгәрешләргә күзәтүләр балаларның хәтерен яхшырта, игътибарны үстерә, әйләнә-тирә дөньяга сакчыл караш тәрбияли.





## АРЧА «1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» ТАБИГАТЬ САГЫНДА!








Арча шәһәренең беренче балалар бакчасында экологик тәрбиягә багышланган бәйрәм- "Урманга сәяхәт! " квест-уены булып узды. Уенда бакчаның мәктәпкә әзерлек төркеме балалары катнашты. Балалар сорауларга җавап бирделәр, аю белән бүренең , убырлы карчыкның биремнәрен үтәделәр.
Бәйрәмнең махсус кунагы Биоресурслар буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетының "Ашыт" табигый тыюлыгы белгече Габдрахманова Гөлнара Ильяс кызына да бәйрәм бик ошады. Ул балаларга махсус бүләкләрен тапшырды, табигатьне сакларга кирәклеген тагын бер кат искәртеп узды.

## АБДУЛЛА АЛИШ—БАЛАЛАР ӘКИЯТЕ ОСТАСЫ

15 сентябрь халкыбызның батыр улы Абдулла Алишның туган көне.
Шул уңайдан безнең балалар бакчасында, бөек шагыйрь Абдулла Алишны искә алу кичәсе узды. Мәктәпкә әзерлек, уртанчылар төркемнәре бергәләшеп, музыка залында , язучының тормыш юлы, иҗаты белән таныштылар. Алишның балалар өчен язылган әкиятләреннән өзекләр карадылар. җырлар җырладылар, уеннар уйнадылар. Әкиятләр аша әниләргә карата ихтирамлылык, дуслыкның кадерен белү, сер саклый белү кебек уңай сыйфатлар тәрбияләргә мөмкинлек биргән әлеге кичә балаларда матур тәэсирләр калдырыр дип өметләнәбез.

